МБГБУ „Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
Иске Чәчкаб төп гомуми белем бирү мәктәбе“

# Инша-фикерләү

## Тема: „Бүгенге көн укытучысы әле укытучы гына була алмый: тарихчы, физик, химик...“

Татар теле һәм әдәбияты
һәм инглиз теле укытучысы
Вилданова Илсинә Илназ кызы

2018 нче ел

„Яхшы укытучы булу өчен,
укыткан фәнне һәм
укучыларны яратырга
кирәк".

В. Ключевский

Бүгенге көн укытучысы – ул үз фәнен яхшы белүче генә түгел, ә төрле укучыга якын килеп, аңа салынган сәләтне күрә белүче. Әлбәттә, моның өчен укытучыга, беренче чиратта үз фәненең укыту методикасын белергә, заманча белем бирү технологияләрен кулланырга кирәк.

Болардан тыш, заманча укытучы үзенең авыр хезмәтендә ярдәм итә алырдай иң кирәкле сыйфатларга ия булырга тиеш. Мисал өчен, мондый сыйфатларга стресска каршы тора алу һәм хезмәт сөючәнлекне кертергә мөмкин. Минемчә, әгәр дә кешедә әлеге сыйфатлар табылачагын булмаган икән, укытучы һөнәре турында сүз дә булырга мөмкин түгел.

Педагогика фәненнән ерак торучы күп кенә кешеләр укытучы һөнәренең ни дәрәҗәдә тырышлык сорый торган һәм авыр хезмәт икәнлеген күз алдына да китерә алмыйлар. Көненә алты-җиде сәгать бар кешенең күз алдында булып, шул ук вакытта бөтенләй капма-каршы кешеләр белән аралашу. Бик күпләр берьюлы берничә бала белән аралаша алмый. Кайвакыт бер бала белән генә дә уртак тел таба белү зур тырышлык сорый.

Әлбәттә, укытучы һөнәренең уңай яклары да

күп. Үсеп килүче буын белән даими рәвештә аралашып тору өчен заман белән һәм заманча яшьләр белән бергә атларга кирәк. Бу укытучыга күңелендә һаман да яшь булып калырга мөмкинлек бирә. Моның турында балалар үзләре дә әйтәләр. „Бүгенге көн укытучысы нинди булырга тиеш?" дигән сорауга күпчелек „бүгенге көн укытучысы заманча яшьләр белән уртак тел таба алырга тиеш" дип җавап бирделәр. „Бүгенге көн укытучысы информацион технологияләр белән дус булырга һәм аларны куллана белергә тиеш" дигән җавап та бертавыштан кабул ителде. Укытучыга хас сыйфатлар арасында кешелеклелек, гаделлек, һәм, сәер яңгыраса да, таләпчәнлекне атадылар. Укучылар фикеренчә, укытучыда юмор хисе булу да мөһим роль уйный. Димәк, укытучы кирәгеннән артык таләпчән һәм кырыс булырга тиеш түгел. Әлеге сыйфатларны башлангыч сыйныфлар гына түгел, югары сыйныфлар да билгеләп үттеләр.

Димәк, XXI гасыр укытучысы нинди булырга тиеш соң?

Беренчедән, укытучы һөнәрен сайлаганда, студент елларында ук, үзенә укытучы урынына күз карарга кирәк.

Икенчедән, үзенең һөнәренә дөрес сайлавына ышангач, үзең өстендә һәм укучылар өчен бик күп эшләргә кирәк. Көтелмәгән нәтиҗәләргә ирешү өчен бик күп көч һәм тырышлык кирәк. Нәтиҗә үзен күрсәтчен өчен бик күп вакыт үтәргә мөмкин, ләкин ул һич-

тиксез булачак.

Өченчедән, үсеп килүче буынга тәрбия бирүдә сыйныфтан тыш һәм дәрестән тыш чараларның әһәмияте зур. Укучы-укытучы мөнәсәбәтләренең беренче баскычында нәкъ алар төп рольне уйныйлар. Сыйныфтан тыш чаралар укытучыга балаларда фәнгә карата кызыксыну уятырга булышлык итә. Укытучының белем һәм күнекмәләрен үстерүдән тыш, бу дөньяга ярашкан шәхес, үз иленең ватанпәрвәре, туган ил сакчысы тәрбияләү төп бурычы булып санала. Әлеге бурычларга укытучы төрле фәнне – физиканы, химияне, тарихны – өйрәткәндә дә ирешә ала. Моның өчен һәр укучының күңелен аңлый белергә, гаиләсендәге, яшьтәшләре, укытучылары белән мөнәсәбәтләрен сизә һәм күрә белергә кирәк.

Нинди генә заманда яшәсәк тә, без – укытучылар, һәрвакыт кеше булып калырга тиешбез! Укучылар – алар балалар, шуңа күрә без бары тик белем бирү өлкәсендә генә эшли алмыйбыз. Алар безнең аша дөньяны таный белергә, аның төп асылына төшенергә өйрәнәләр, шуңа күрә һәр укытучы авыр вакытта ярдәмгә килер, тыңлар, кирәк вакытта төпле киңәшен бирер. Тирәнрәк уйлап карасак, без рәсем дә ясыйбыз, биибез дә, җырлыйбыз да, уйныйбыз да. Укытучы – ул фәнне генә өйрәтүче түгел, үзеңне төрле яктан сынап карарга мөмкинлек бирүче күпьяклы һөнәр икәнлегенә тагын бер кат ышанабыз.
Шуңа күрә мин үз хөрмәткә лаек һөнәр – укытучы

һөнәрен сайлаганга бер дә үкенмим!

Укытучы кулында кечкенә бала язмышы һәм аның нинди булуы укытучыдан да тора. Балалар өчен беренче урында фән түгел, ә укытучысы тора. Укытучының укучы күңелендәге ялкынны ничек кабызып җибәрүенә карап, аның фәненә карата ярату да шулай уяначак.

Йомгак ясап әйткәндә, кешелек эшчәнлегенең барлык өлкәләрендә дә чын профессионаллар торырга тиеш. Профессионалга хас иң төп сыйфат – ул үз-үзеңне камилләштерүгә омтылу. Мин үземнең укытучы эшчәнлегемдә һәрвакыт шушы карашка таянып эшлим. Әлеге уңайдан бөек Ч. Диккенс сүзләрен искә төшереп китәсем килә: „Һәр дә кеше башкаларга камилләшергә ярдәм итми икән, ул кеше үзе чын мәгънәсендә камилләшеп бетә алмый". Әлеге сүзләргә кеше яшәешенең мәгънәсенә карата тирән фәлсәфи мәгънә салынган. Укытучы да бит кеше. Ул үсеп килүче буынга бар яктан да үрнәк булырга тиеш. Мин үземнең укучыларымны әзер нәтиҗәләр көтеп тормаска, ә бар нәрсәгә дә тырышлык ярдәмендә ирешергә өйрәтергә телим. Укытучы буларак минем төп бурычым – үзүсешкә омтылышка өйрәтү. Нинди генә заман булмасын, укучылар белем алуның үзләре өчен мөһимлеген, табигатьтән бирелгән сәләтне үстерергә кирәклеген аңларга тиеш.